Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы

21 март, 2014 ел
№3

## Әлеге санда:



Тарих сәхифәләре (2 нче бит )



Сәламәт тәндә—сәламәт акыл! (3 нче бит)




Илһам канатында (4 нче бит )



Мәктәп дәрьясында…

(7 нче бит)



## Яз килә

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы -
Сагынып көткән яз килә.

Әйтегезче,кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк.

Көннәр җылы, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә,
Җәйге шатлык, көзге бәхет
Яз белән бергә килә.

**М.Мазунов**

## Мәктәп хәбәрләре:

1. «Туган телләр» айлыгында 5 нче һәм 6 нчы сыйныфлар өчен К.Насыйри музеена сәяхәт оештырылды.
2. «Казан сандугачы» исемле шәһәр конкурсында Әхмәдуллина Кадрия (3 нче Б) һәм Сәйдә (1 нче Б), Валеева Диләрә (9 нчы М) 2 нче урынны, Абдуллина Зәринә (5 нче М) һәм Фазлыев Эмиль ( 5 М) 3 нче урынны алдылар.
3. «Татар кызы» конкурсында Валеева Диләрә Идел буе районында 1 нче урынга лаек булды.
4. 5 нче сыйныф укучылары Крымов Денис, Инсафетдинов Эмиль, Докукин Аркадий Г.Тукай музеенда тупланган материаллар белән аеруча кызыксынып китеп, 15 февраль көнне Һ.Атласи исемендәге фәнни-гамәли конференциядә уңышлы катнашып, сертификат алдылар. (Җитәкчесе: Инсафутдинова М.Т.). Әлеге конференциядә Абдуллина Зәринә дә сертификатка лаек булды. (Җитәкчесе: Абдуллина Л.Р)
5. “Ике йолдыз» исемле район конкурсында Васянова А.Г. һәм Васянова В.( 6 нчы М) 2 нче урынны, Абдуллина Л.Р. Һәм Абдуллина З.(5 нче М) 3 нче урынны алдылар.
6. «Турникта күтәрелү» конкурсында Александров Н. (10 нчы А), Канцеров Т. (10 нчы Б), Курмаев А. (8 нче М), Якубов Г. ( 7 нче М) Идел буе районында 1 нче урынга лаек булдылар. (Җитәкчесе: Ильясов Т.Г.)
7. «Мин татарча сөйләшәм» дип исемләнгән акция уза. Шул уңайдан 5 нче, 6 нчы сыйныф укучылары туган телебез буенча агитация алып баралар.

## “Истә синең якты гомерең” (М. Җәлил истәлегенә багышланган)

Батыр үлә, үлмәс ат алып,
Батырлыклар белән макталып.
Исемең калсын, үзең үлсәң дә,
Тарихларда укып ятларлык.
М. Җәлил.

Күптән түгел бөтен кешелек дөньясы сөекле шагыйребез, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең зур юбилеен билгеләп үтте. Барлык халыкларның сөекле улы Муса Җәлилнең исеме тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган. Шагыйрь Муса Җәлил үзенең бөтен гомерен туган иленә, туган халкына багышлады. Аның бөтен тормышы — героик тормыш ул. Муса Җәлил шигырьләрендә туган халкының азатлыгы өчен көрәштә үзен корбан итәргә әзер торган көрәшче образы тудыра, үзе дә халык эше өчен соңгы сулышына кадәр аяусыз көрәшә.

Ул халык эше өчен көрәшергә биргән антын тиңдәшсез батырлык, искиткеч ныклык белән үти, үз халкының азатлыгы өчен соңгы тамчы канынача сугыша. Гүзәл тормышын ул туган иле өчен корбан иткәнлегенә нык ышанган хәлдә тәгәлли.

Батырлык һәм илгә тугрылыкны
Шушы үлем белән белдерик, —
ди ул үзе белән бергә тоткынлыкта фашизмга каршы көрәшүче Абдулла Алишка.

Шагыйрь үзенең соңгы сулышын алганда да үлемсез батырлык эшләвенә ышана:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң



Җиңеп үлгән мондый үлемне?

Муса Җәлил үлемнән курыкмый, һәм «бәлки менә шушы үлем безгә мәңге яшәү китерер» дип горурлана. Туган илдә аларның хыяллары чәчәк атачак, алар шуңа инанганнар һәм шуның белән юанганнар.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Муса Җәлил Совет Армиясе сафларына баса. Совет халкы кичергән зур сынау көннәрендә шагыйрь үзенең Ватан алдындагы бурычын тулысынча аңлап эш итә, үзенең үткен каләмен фашизмны тар-мар итү өчен көрәштә иң көчле коралга әйләндерә.

Җырым, синдә минем гәүдәләнде
Илне сөйгән йөрәк тибешем.
Җырым иде антым:
Яшәсәм дә,
Үлсәм дә тик туган ил өчен!

Шагыйрь совет кешеләрен сугышта да, тылда да тулысынча фашизмга каршы көрәшергә чакыра. Бөек бәрелешләр барган утлы кырларда, фашистлар яудырган туплар астында йөргәндә, Муса Җәлил үзенең әсәрләрендә күперне шартлатып, дошман утыннан һәлак булган партизанның батырлыгын сурәтли, фашистлар тарафыннан үтерелгән сабый өчен соңгы тамчы канына кадәр сугышырга ант биргән солдатлар турында җырлый.

Муса Җәлил — патриот шагыйрь. Халкыбызның олы җанлы батыр улын, бөек гражданинын бөтен прогрессив кешелек зур ихтирам белән телгә ала.

Каның белән язган җырларыңны
Тетрәп укый сине бөтен җир,
Буыннардан буыннарга килер,
Мәңге үлмәс, Муса, синең җыр!

**Мөхәррирләр**








## Хуш, Сочи!

Сочи Олимпиадасы тәмам. Анда яңа йолдызлар кабынды, яңа рекордлар куелды. Русия җыелма командасы, 13 алтын, 11 көмеш, 9 бронза – гомум 33 медаль яулап, турнир таблицасының иң югары баскычына күтәрелде. Моңа кадәр ватандашларыбыз 1994 елда гына яхшы күрсәткечкә ирешә алган иде – Норвегиянең Лиллехаммер шәһәрендә 23 –11 алтын, 8 көмеш, 4 бронза медаль яуладылар.

Шуннан бирле русиялеләрнең гомум турнир таблицасында беренче урынга чыкканы булмады. Медальләр саны буенча СССРны да узып киттек: СССР вакытында иң күбе 29 медаль яуланган булган. Русия җыелма командасы Норвегиянең 1952 елда Осло шәһәрендә ирешкән уңышын кабатлады: Олимпиаданы үткәрүче ил гомум медаль зачетында да, алтын медальләр саны буенча да лидерлыкны яулады.

Ничек итсәк иттек, бу уеннарны лаеклы үткәрдек, башка илләр арасында оятка калмадык.

Күңелләребездә ватанпәрвәрлек хисләре сүнмәгән әле: Русия спортчылары стартка чыккан саен ихлас күңелдән аларга җиңү теләп борчылдык. Спортчыларның җиңүләрен үзебезнең җиңү кебек кабул итеп, алар белән бергә шатланып еладык, җиңелгәндә алар белән бергә көендек. Русия спортчыларыннан кала мин кечкенә илләрдән чыккан бөек спортчылар өчен дә җан аттым. Әйтик, Дарья Домрачева ул – бөек спортчы. Өч тапкыр Олимпиада чемпионы. Шулай ук Уле-Эйнар Бьерндален да – җиде тапкыр Олимпиада чемпионы.

Шулай итеп, Сочи олимпиадасы илебез горурлыгына әвереде!

**Материалны мөхәррирләр әзерләде**

| Урын | Илнең исеме | Алтын медаль | Көмеш медаль | Бронза медаль | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Россия | 13 | 11 | 9 | 33 |
| 2 | Норвегия | 11 | 5 | 10 | 26 |
| 3 | Канада | 10 | 10 | 5 | 25 |
| 4 | АКШ | 9 | 7 | 12 | 28 |
| 5 | Нидерландлар | 8 | 7 | 9 | 24 |






# Илһам канатында

**3 нче чирек үзенең вакыйгаларга бай булуы белән истә калыр. Вагыйгаларның үзәгендә «Телләр айлыгы» на үткәрелгән чаралар да укучыларның игътибарыннан читтә калмады.**

## Туган телем йөрәгемә якын

Татар телендә матур итеп, әдәби телдә сөйләшер өчен матур әдәбиятны күп укырга кирәк. Иң беренче чиратта классик язучылар әсәрләре, мәсәлән, Габдулла Тукайны, Мостай Кәримне, Әмирхан Еникине, Һади Такташны, Шәүкәт Галиевны, Туфан Миңнуллинны һәм башка авторларның әсәрләре белән танышырга кирәк. Шул ук вакытта “Ялкын”, “Сабантуй” журналларын уку да күп файда бирә дип уйлыйм. Телевизордан һәм радиодан татар телендә булган тапшыруларны карау һәм тыңлау да, үз телебездә матур итеп сөйләшергә өйрәтә. Анда татар интеллигенциясенең, галимнәрнең сөйләмен ишетәбез.

Гаиләдә әти-әниләр белән дә татар телендә сөйләшергә кирәк. Син дөрес сөйләшмәгән очракта, алар сине төзәтәләр. Җәй көне авылда булу да, сөйләм телен үстерергә ярдәм итә.

Минемчә, иң мөһиме, мәктәптә укытучы апалар безгә татар теленең барлык нечкәлекләрен аңлатканда бик игътибар белән тыңларга кирәк. Матур итеп сөйләшкән кеше белән аралашу бик рәхәт. Әдәби телдә сөйләшергә һәркем омтылырга тиеш.

**Радик Идрисов,**
**5 нче сыйныф укучысы**

## Минем телем болай да бай!

Хәзерге заманда сөйләм үзгәреш кичерә. Татар яшьләре, татарча сөйләшкән вакытында да рус сүзләрен кыстырып сөйләшәләр. Мондый күренеш бары тик безнең халыкта гына түгел, ә башка халыкларда да сизеләдер дип уйлыйм, чөнки хәзер төрле илләргә чыгып китеп уку, эшләү, ял итеп кайту өчен чикләр юк, бер генә нәрсә – акча кирәк. Мәсәлән, руслар да инглиз теленнән күп кенә сүзләрнне кулланып сөйләшәләр. Шуңа бер мисал: ризалашканда, алар: “ладно, хорошо” дип әйтәсе урынга инглизчә “Ок” диләр. Ләкин бу әле зур проблема түгел, күп кенә кешеләр культурасыз сөйләшәләр, бер дә кирәкмәгән мәгънәсез, ямьсез сүзләр кыстыралар. Бәлки алар шулай эшләп, үзләрен генә күрсәтмәкче булалардыр? Ләкин ни өчен алар шулай эшлиләр? ? Шундый ямьсез сүзләр кулланып сөйләү – ул кешенең тәрбиясезлеге турында сөйли.


Ә кайбер кешеләрнең ямьсез сүзләр белән сөйләшүләре, аларның гадәтләренә кереп китә.

Сөйләм культурасы булырга тиеш. Кешеләргә күбрәк китаплар укырга кирәктер дип саныйм, чөнки классик язучыларны укып, бай хәзинәгә ия буласың.

Укучылар, ямьсез сүзләр кулланып сөйләшмәгез! Сез бары тик үзегезне һәм телегезне генә мыскыллыйсыз.

Мин, мәсәлән, матур әдәби телдә сөйләшкән кешеләргә сокланам.

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы сыйныф укучысы**



## Иң якын кешем – әнием

Һәр кеше өчен дөньяда иң якын кеше ул әни. Әни! Бу сүзгә күпме мәхәббәт, сабырлык һәм горурлык салынган. Ул безгә иң газиз, кадерле, якын кешебез, чөнки ул мине, тугач та, күкрәк сөте белән имезгән, миңа туган телне дә өйрәтүче ул. Әниемнең исеме Нәргизә. Аңа 41 яшь. Ул кафеда эшли. Күзләре аның көрән төстә, керфекләре дә озын, матур. Мин аны бик нык яратам, чөнки бу дөньяда минем өчен аңардан да кадерлерәк кеше юк. Ул тәмле итеп ашарга пешерә, аның ризыкларын ашасаң, телеңне йотасың. Берәр нярамаган эш эшләсәм дә, әни мине барыбер ярата, гафу итә.

Минем өчен әнием иң кадерле, иң якын, иң матур кеше. Тормышымны әниемнән башка күз алдыма китерә дә алмыйм. Үзем әнисез үскән балаларны кызганам, чөнки алар минем шикелле ана назы тоеп үсмиләр.

**Гөлмирә Батталова,**
**6 нчы сыйныф укучысы**



## Ата - ананы тыңлаган – адәм булган, тыңламаган – әрәм булган

Яшәгәннәр ике дус: Илшат белән Марат. Алар урманда уйнарга яратканнар. Бер эссе җәйге көнне Илшат белән Марат урманга йөгереп киткәннәр. Өйдән чыгып китүләре турында әти-әниләренә әйтмәгәннәр.

Менә кич җитә башлаган. Ике дус уйнап та туйганнар, бернәрсә дә кызык булмый башлагач, өйгә кайтырга кирәк икәнлеген искә төшергәннәр. Ләкин уйный -уйный бик нык эчкә кереп киткәннәр икән. Урманнан ничек чыгасын белмәгәч, елаганнар.

Өйдәгеләр инде кайгыра башлаганнар, балаларны эзләргә дип чыгып киткәннәр. Тәмам арып, хәлдән таеп беткәч, урман эчендә: “ Марат, Илшат, сез, кайда?” – дип кычкыра башлаганнар. Бер заман ерактан балаларның тавышлары ишетелгән: “Без монда, килегез!” .

Шулай итеп, балаларны тапканнар. Бу хәлдән соң әти-әниләре и орышканнар, и орышканнар сабыйларын. Хәзер Марат белән Илшат берәр кая чыгып китәсе булса, һәрвакыт зурлардан рөхсәт сорыйлар, чөнки олыларның сүзен тыңларга кирәк. Алар беркайчан да начарлыкка өйрәтмиләр.

**Ләйлә Магеррамова,**
**6 нчы сыйныф укучысы**

## Ялкау Марат

Бер ир белән хатын яшәгәннәр. Аларның өч балалары булган: Марат, Ләйсән белән Зөһрә. Марат бик ялкау булган, мәктәпкә йөрергә яратмаган. Бер көнне әти-әнисе аңа: “Марат, улым, мәктәпкә бар, белем һәрвакыт кирәк ул, үскәч кем буласың соң? Белемле кеше булсаң, зур үрләр яуларсың!” – дигәннәр. Ә малай әниләренә бер шарт куйган: “Әгәр мин мәктәпкә йөрсәм, сез миңа һәркөнне күп итеп кәнфитләр бирә торган буласыз!” – дигән. Нишләсеннәр инде ата-анасы, ризалашканнар.

Икенче көнне Марат иртән иренеп кенә уянган. Өйдәгеләр инде күптән торганнар. Барысы да җыеналар: әниләре эшкә, сеңелләре укырга. Әти-әнисе беренче булып чыгып киткәннәр. Ләйсән белән Зөһрә әллә кайчан киенеп, әзерләнеп беткәннәр, ә Марат һаман киенмәгән. Сеңелләре: “ Без сине көтеп, соңга калабыз, тизрәк җыен, куып җитәрсең безне!” – дип чыгып киткәннәр. Өй, ниһаять, тынган: чабып йөргән, тиз-тиз генә җыйналган кеше дә калмаган. Маратның хәтта, бераз ачуы да чыккан. Шулай итеп, ул бүген дә мәктәпкә бармаска булган, чөнки соңга калган.

Кич җиткән. Менә әниләре дә эштән кайтканнар. Алар Маратның мәктәпкә барганына ышанып, күп итеп кәнфитләр сатып алганнар. Марат, беркем дә күрмәгәндә, кәнфитләрнең күбесен качырып ашаган да, эче авырта башлаган. Сеңелләре аның көне буе өйдә булуы турында сөйләп биргәндә, инде соң була, кәнфитләр ашалып беткәннәр. Бөтен ялган ачылгач, Маратка бик оят булган. Өйдәгеләр аны ачуланганнар. Ул шунда гына алдаларга ярамаганлыкны аңлаган. Әгәр дә сеңелләре дөреслекне сөйләмәсәләр, ялганы берничә атнага сузылган булса, нәрсә булыр иде икән?

**Айгөл Марданова,**
**7 нче сыйныф укучысы**

### Күңелле Сабантуйлар

Сабантуй бәйрәменә
Ак калфакларын киеп,
Матур кызлар килгәннәр.
Малайлар да сынатмаган,
Сабантуйда җиңгәннәр.

Чулпылар, түбәтәйләрне
Бүләк итеп биргәннәр.
Балалар бу хөрмәткә
Чын-чынлап сөенгәннәр!

**Ләйлә Магеррамова,**
**6 нчы сыйныф укучысы**

## Безнең мәктәптә “Коймаклар көне”

Масленица – җиде көн буена үткәрелә торган бәйрәмнәрнең берсе. Әлеге бәйрәмнең төп символы булып кайнар, тәмле коймаклар тора. Русларда кайнар коймаклар кояш символын да аңлата, чөнки кышны озатып, барлык халык язның килүен каршылый.

Масленицаны һаман да күп кенә Европа илләрендә уздыралар. Баштанрак ул бәйрәм “Яз башланды” дигән мәгънә йөрткән булган икән. Әлеге бәйрәмнең җиденче көнендә, саламнан ясалган, карачкыны яндырганнар. Янган карачкы белән шулай ук үзләренең иске киемнәрен, әйберләрен дә яндырып, “яңа тормыш” башланыр дип ышанганнар.

Безнең мәктәптә “Коймаклар көне” бәйрәме үтте. Бу көнне барлык укучылар да өйләреннән коймаклар пешереп алып килгәннәр иде. Тәнәфес вакытында бер-берсен сыйладылар, ә кайбер сыйныфлар коймакларын саттылар да.

Мәктәбебездә төрле милләт кешеләре укысалар да, барлык бәйрәмнәрне дә дус, тату, кызык итеп үткәрәбез.

Әлеге бәйрәм кешеләрне очраштыру, дуслаштыру мәгънәсен дә йөртә. Бу көнне кешеләр бер-берсеннән гафу сорарга тиеш булалар икән.

**Айсылу Фаезова,**
**8 нче сыйныф укучысы**










## *Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз!*

“Нәүрүз” сүзе фарсыча “яңа көн” дигәнне аңлата. Урта Азиядә, Иранда, Әфганстанда һәм кайбер башка илләрдә бик борынгыдан килгән Яңа елны каршылау бәйрәме ул. Нәүрүз көн белән төн тигезләшкән чорга – 21-22 мартка туры килә.



XIX гасырда Нәүрүз көннәрендә (ул берәр атнага, ун көнгә сузылган) йорттан-йортка кереп "нәүрүз әйтеп” йөрү гадәте булган. Моны укучы балалар башкарган. Нәүрүз такмагын укып, яки яттан әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр.

Бүген көн тиң төннәргә
Урын юк һич көнләргә
Без дә тиң, без дә тигез!
Мөбарәк Нәүрүз!-дибез.

Безнең мәктәптә дә “Нәүрүз” бәйрәме гөрләп үтте. Иң элек ул спорт залында татар милли уеннары, ярышлары белән башланып китте.

Спорт залында бәйрәм тантанасының башлануын игълан итү өчен, кадет сыйныфлары барабаннар, трубалар белән уйнадылар. Бу исә, әлеге музыкаль кораллар ярдәмендә барлык халыкны бәйрәмгә чакыру кебек яңгырады.



10 нчы һәм 9 нчы сыйныфлар үзара көч сынаштылар. 10 нчы сыйныф командасының исеме «Язгы тамчылар», ә 9 нчыларның «Кар йомарламы» исемле иде.

«Капчык белән чабу», «Батырлар көч сынашуы», «Канат тарту» эстафеталарында «Язгы тамчылар» командасы үзенең көчле, бердәм команда булуын раслады.

Ярышлар бетүгә, баллар саналып, «Язгы тамчылар» командасы җиңеп чыкты. Димәк, тиздән яз җитәчәк, кыш инде үзенең көчсезлеген тагын бер кат раслады.




**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы сыйныф укучысы**

# Мәктәп хәбәрләре

### Яз

Туктап сана,
Тамчы тама:
Тып,тып,тып.

Төшә-төшә
Бозны тишә:
Тып,тып,тып.

Яз бу, ишет,
Кага ишек:
Тып,тып,тып.

Ш.Галиев

### «Яз бәйрәме— Нәүрүз!»

Без «Нәүрүз» бәйрәмендә җанатарлар булдык. Читтән өлкән сыйныфларның ярышуларын карарга бик тә кызык булды. Командаларның, үзләре белән таныштырганда, бии-бии чыгуларын, тырыша-тырыша уйнауларын күзебезне дә алмыйча карап торык.

«Язгы тамчылар» командасы өчен кычкырып, тавышыбыз бетте. Ярышлар беткәндә, үзебез дә хәлдән тайдык.

**Алия Галимҗанова,**
**6 нчы сыйныф укучылары**




### Бәйрәм дәвам итә

Бәйрәм тантанасы актлар залында дәвам итте. Сәхнәдә төрле сыйныф укучылары җырладылар, шигырьләр сөйләделәр, курайда моңлы көй уйнап күрсәттеләр.

Бәйрәм ахырында Кыш бабай, үзенең китәсен аңлагач, балаларга кызыл капчыгыннан күп итеп кәнфитләр сибеп калдырды. Бала-чагалар шатланышып, кәнфитләрне җыярга дип чабыштылар.

«Нәүрүз» бик күңелле үтте.

**Алсу Әхмәдуллина,**
**6 нчы сыйныф укучысы**



### Яз житә

Кояш көлеп карый безгә,
Күзләр чагыла.
Елгалардан бозлар ага
Диңез ягына.
Яз, яз, яз житә,
Тәрәзәне ачтылар.
Тып-тып-тып итә
Эре-эре тамчылар.
Агачка кунып чыпчыклар
Чыелдашалар.
Яшькелт-кара сыерчыклар
Әй жырлашалар.

**Ф.Кәрим**



# Эш беткәч, уйнарга ярый

**23 нче февраль белән!**

Ватанны саклаучылар көне—
Чын ирләрнең бәйрәме!
Туар таңнарыбыз тыныч булсын,
Артсын бәхет-шатлык бәйләме.
Тыныч булсын сезнең көнелегез,
Эшләрегез барсын, гөрләсен.
Гомер буе сезнең йөрәкләрдә
Яшәү дәрте сүнми дөрләсен.
Байлык - муллык телик тагын сезгә,
Барча теләк - ихлас күңелдән.
Телик әйдә тагын саф мәхәббәт
Тормыш яме артсын бүгеннән!



**8 март – Халыкара хатын-кызлар көне** – иң якты, матур бәйрәмнәрнең берсе. Язның беренче бәйрәме уңаеннан, кояш кебек ягымлы, игелекле, аяз көн кебек якты күңелле, чәчәктәй гүзәл затларыбызга күңел түреннән чыккан ихлас котлау сүзләрен һәм иң изге теләкләребезне җиткерәбез



## Котлыйбыз!

**78 нче мәктәп укытучылары һәм укучылары ягымлы, кояшлы яз көннәренә туры килгән туган көннәрен билгеләп үтүче укытучыларны котлый:**

**Гришина Татьяна Владимировна**
**Майорова Евгения Федоровна**
**Миннегалиева Әсфирә Хәбировна**
**Голованова Татьяна Васильевна**
**Рәхиева Әлфия Нәзгатовна**
**Нуриева Гөлнара Гаптелфартовна**
**Гареева Светлана Александровна**
**Петрова Надежда Геннадьевна**
**Урманчеев Таһир Шамилевич**
**Шакирова Резеда Фаиковна**
**Коваленко Людмила Николаевна**
**Сибгатуллина Альбина Наилевна**

**Зур бәхетләр юлдаш булсын Сезгә,**
**Көннәрегезне шатлык бизәсен.**
**Сәламәтлек – ярты бәхет, диләр,**
**Шушы бәхет читләп үтмәсен.**
**Бәйрәм белән тәбриклибез,**
**Телибез бәхет кенә.**
**Нурлы булсын йөзләрегез,**
**Бәхетләр иңеп кенә!**



**Мөхәррирләр:** С.Сөләйманов, Ф. Айсылу, Я. Гадел, Г.Батталова, М. Айгөл, Р. Идрисов, Я. Илгиз, А.Әхмәдуллина, Д.Мостафаева, С. Ильвина, Х. Рамил, М.Ләйлә. Г.Алия
**Консультант:** Л. И. Исмаилова

*Мәктәбем минем*

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139
тел./ факс 268-58-61
E-mail: school_7878@mail.ru S78kzn@edu.tatar.ru
Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:
https://edu.tatar.ru/priv/school78.htm/page813169.htm
Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:
lyutsiya_906@mail.ru